**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«12» ноябрь 2019 ел** **№ 315**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый координацияләү советы турында» 2018 елның 12 февралендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый Координация советы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 21.07.2014 ел, № 212-ФЗ Федераль закон нигезендә, **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый координацияләү советы турында» 2018 елның 12 февралендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый Координация советы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның бишенче абзацында «районның максатчан программалары» сүзләрен «муниципаль программалар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Яшьләр Координация советы әгъзалары була алмый:

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар;
- суд карары нигезендә эшкә яраксыз дип табылган затлар;
- хөкем ителгән затлар;
- ике ил гражданлыгы булган затлар;

- «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмый торган башка затлар.».

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә: http://aznakaevo.tatar.ru// веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Р.Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов